**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.08.2015 Балык Бистәсе штп. № 212пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы авыл җирлеге территориясендә урнашкан социаль файдаланудагы торак фондының торак урыны наем шартнамәсе буенча бирелә торган торакның гомуми мәйданы күләмен билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 91.15 статьясындагы 3 өлеше, , «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 3, 4 өлешләре,1 өлешнең 6 пункты, «Социаль файдаланудагы торак фондның торак урыннарын наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 5 өлеше, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 8 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты, «Торак урыны мәйданын бирү һәм исәпкә алу нормасын билгеләү турында» Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 28.07.2011 ел, №281пи карары нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы авыл җирлеге территориясендә урнашкан Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыны наем шартнамәсе буенча бирелә торган торакның гомуми мәйданын бер кешегә 18 кв.метр күләмендә, ләкин ялгыз яшәүче граждан өчен 33 кв. метрдан ким булмаган күләмдә һәм ике кешедән торган гаилә өчен торак урынының гомуми мәйданыннан 42 кв. метрдан ким булмаган күләмдә билгеләргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Д. А. Низамовка йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын башкаручы Р.Х.Хәбибуллин